**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552) 3-44-22,факс (85552)3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

________________　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　________

**«Актаныш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча Бердәм комиссия турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 05 апрелендәге ПР-65 номерлы Башкарма комитет җитәкчесе карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, бюджет һәм бюджеттан тыш акчалардан нәтиҗәле файдалану, намуслы конкуренцияне үстерү, муниципаль ихтыяҗлар өчен заказларны урнаштырганда хәбәрдарлык һәм үтә күренмәлелекне тәэмин итү максатларында, кадрлар үзгәрешенә бәйле рәвештә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 05 апрелендәге ПР-65 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәреш кертергә. «Актаныш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча бердәм комиссия турында нигезләмәне раслау хакында» түбәндәге редакциядә, 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкченең беренче урынбасары　　　　　　　　　　　　　　　　Л.Ф.Нурлыева

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
_______________ №_____
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча бердәм комиссия составы

| | |
|---|---|
| Шакирова Алия Миндыгали кызы | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының комиссия рәисе, эшләр идарәчесе; |
| Зарипова Алия Илгиз кызы | Комиссия рәисе урынбасары, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының сатып алулар секторы мөдире; |
| Дехконова Фәүзия Фирдәвис кызы | Комиссия секретаре, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының сатып алулар секторы баш белгече; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Гарипов Руслан Илус улы | Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары; |
| Мосабиров Шамил Алмаз улы | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы урынбасары; |
| Мирзашарипова Ойгуль Миннефәрит кызы | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгы; |
| Хузин Рамил Радист улы | «УКС» МУП директоры. |